24. Kharisova, Ch. M. (2014). *Tatar telendә syzlәrne tөrkemlәү printsiplary* [Principles of Word Grouping in the Tatar Language]. Millimәdәniәt. Pp. 155– 157. Qazan, Afyonkarahisar. (In Tatar)

25. Khisamova, F. M. (2006). *Tatar tele morfologiyase: Yugary uku iortlary өchen dәreslek* [Morphology of the Tatar Language: A Textbook for Universities]. F. M. Khisamova. 335 p. Kazan, Mәgarif. (In Tatar)

# ТАТАР ҺӘМ БАШКА ТӨРКИ ТЕЛЛӘРДӘ РӘВЕШ СҮЗ ТӨРКЕМЕН ДИАХРОНИК АСПЕКТТА ӨЙРӘНҮ

**Гөлнара Расиховна Шакирова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
shakirova25@mail.ru

Мәкалә татар һәм башка төрки телләрдә рәвеш сүз төркемен диахроник аспектта өйрәнүгә багышлана. Төрки телләр белеме үсеше тарихында бу сүз төркеме галимнәрнең игътибарын һәрвакыт җәлеп итеп торган. Татар телендә исә рәвешләр XIX гасыр башында өйрәнелә башлый. Мәкаләдә Г. Алпаров, И. Гиганов, Н.К. Дмитриев, А. Казем-Бек, А.Н. Кононов, К. Насыйри, Г. Нугайбек, А. Троянский кебек танылган тел белгечләренең хезмәтләрендәге әлеге мәсьәләгә кагылышлы төрле фикерләр һәм принциплар карала. Рәвешнең мөстәкыйль сүз төркеме буларак формалашуы, аның лексик-семантик төркемнәре белән бәйле каршылыклы

фикерләр, әлеге тел берәмлегенең башка сүз төркемнәре белән мөнәсәбәте турындагы бәхәсле аспектлар яктыртыла. Мәкаләдә бу мәсьәлә буенча теоретик материалларны системалаштыруга омтылыш ясала.

**Төп төшенчәләр:** татар теле, мөстәкыйль сүз төркеме, диахроник аспект, рәвеш, тел белеме, морфология

## Кереш

Төрки телләрдә сүз төркемнәрен өйрәнүгә күпсанлы хезмәтләр багышланган, ләкин шуңа да карамастан, әлеге проблема иң катлаулы һәм бәхәсле мәсьәлә булып кала [1, б. 13; 2, б. 128]. Сүз төркемнәре арасында рәвеш үзенчәлекле урын алып тора. Төрки телләрнең морфологик системасында әлеге сүз төркеменең урыны аның мөстәкыйль сүз төркеме буларак чагыштырмача соңрак формалашуы белән бәйле [3, б. 203]. Бу үзенчәлек рәвешләр белән башка сүз төркемнәре арасында ачык чикләрнең булмавы, төрле сүз төркемнәре белән рәвешләр арасында торган аерым сүз формаларының булуы белән аңлатыла (Д.Г. Тумашева, Ф.М. Хисамова, Ч.М. Харисова). Рәвеш сүз төркеменең морфологик һәм грамматик категорияләре булмау аны мөстәкыйль сүз төркеме итеп карауны кире кагуга сәбәп була. Морфологик яссылыкта рәвешләрне, бер яктан, сыйфатлардан, икенче яктан – исемнәрнең кайбер грамматик формаларыннан, шулай ук ярдәмче сүз төркемнәреннән һәм фигыльләрнең хәл фигыль формаларыннан аеру берникадәр авырлыклар китереп чыгара, рәвешне аерым сүз төркеме буларак танымауга, әлеге сүз төркемнәрен бутауга сәбәп була [4, б. 14]. Бу уңайдан, рәвеш сүз төркеменең татар һәм башка төрки телләрдә формалашуын лингво-тарихи аспектта күзәтүнең, XIX гасыр башында дөнья күргән беренче татар теле грамматикаларыннан башлап, хәзерге грамматикаларга кадәр диахроник планда өйрәнүнең кыйммәте зур, чөнки ул телчеләрнең әлеге сүз төркеменә мөнәсәбәтен динамикада, үсештә карарга мөмкинлек бирә.

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Мәкаләнең фәнни-теоретик нигезен Г. Алпаров, И. Гиганов, Н.К. Дмитриев, А. Казем-Бек, А.Н. Кононов, К. Насыйри, Г. Нугайбек, А. Троянский, Д.Г. Тумашева, Ч.М. Харисова кебек күренекле тел белгечләренең хезмәтләре, сүз төркемнәрен өйрәнүгә кагылышлы төрле фикерләре, эзләнүләре тәшкил итә. Тикшеренү барышында чагыштыру, тасвирлау, күзәтү һәм анализ методлары кулланылды.

## Фикер алышу

Татар тел белемендә рәвешләр XIX гасыр башында өйрәнелә башлый [3, б. 203]. И. Гиганов, А. Троянский, К. Насыйри, Г. Нугайбәк, Г. Алпаров, М. Корбангалиев, В.Н. Хангилдин кебек галимнәребезнең хезмәтләрендә әлеге сүз төркемен тикшерүгә аеруча зур урын бирелә.

Беренче татар грамматикасы авторы И. Гиганов рәвешнең аерым сүз төркеме икәнлеген искәртеп үтә, «Татар теле грамматикасы» исемле хезмәтендә «рәвеш – фигыльләр һәм исемнәр алдыннан килеп, төрле хәлләрне белдерүче сүз төркеме», дип билгели [5, б. 176]. Галим рәвешләрне унҗиде мәгънә төркемчәсенә аера. Болар: вакыт, сыйфат, урын, микъдар, сан, тәртип, юклык, охшату, икеләнү, тизлек, төрлелек һ.б. рәвешләр. Бу урында И. Гигановның рус теле грамматикасына нигезләнүен билгеләп үтәргә кирәк. Түбәндәге мисаллар да моны раслап тора: *яхшы – хорошо, иң, борын – прежде, шулай – так, юк – нет, менә – вот, чык – вон.* [5, б. 177-178]. Шулай итеп, әлеге сүз төркеменә кергән сүзләр арасында сыйфатлар, фигыльләр, күрсәтү алмашлыклары, кисәкчәләр һәм рус телендә өлешчә рәвеш мәгънәсен белдергән башка сүзләр бар.

А. Троянский исә үзенең грамматикасында рәвешләрне И. Гиганов кебек үк классификацияли [6, б. 130] һәм хезмәтенең икенче басмасында рәвешләрнең – «эш яки билгенең билгесен яки хәлен белдерүче сүзләр» булуы турында хәбәр итә [7, б. 64]. Күргәнебезчә, әлеге билгеләмә рәвешләрнең бүгенге грамматикаларда тәкъдим ителгән билгеләмәсенә бик якын тора. А. Троянский рәвешләрнең 12 төркемчәсен аерып күрсәтә, аларга әлеге сүз төркеменә кергән сүзләрдән тыш исемнәр, сыйфатлар, бәйлекләр, алмашлыклар, кисәкчәләр һәм модаль мәгънәле сүзләр дә кергән. Алар арасында, мәсәлән, *юк – нет, менә – вот, ни өчен – зачем, кебек – словно, ничә – сколько, әллә – или* кебек сүзләр бар [7, б. 64–68].

Казан лингвистика мәктәбенең күренекле вәкиле А. Казем-Бек үзенең грамматикасында сыйфатлардан һәм исемнәрдән ясалган

рәвешләрне; -*ча / -чә* кушымчалары ярдәмендә ясалган рәвешләрне; һәм гарәп теленнән кергән рәвешләрне аерып күрсәтә. Әлеге сүз төркеменең алты семантик төркемчәсе булуын ассызыклый. Болар: вакыт (*кичә – вчера, бүген – сегодня, берсекөн – послезавтра*), урын (*кайда – где, моннан – отсюда, туры – прямо*), сорау (*ни өчен – зачем, шулаймы – так ли, ничек – как*), сыйфат (*чибәр – красивый, һәйбәт – хороший, яман – плохой*), раслау (*алай – так, шулай – так, әйе – да*), кире кагу (*ялган – лживый*) [8, б. 366–373]. Әлеге сүз төркеменә галим шулай ук *илә* сүзе кулланылган төзелмәләрне һәм -*дан* кушымчалы сүзләрне дә кертеп карый. Нигездә, галим рәвешләрнең ясалыш үзенчәлекләрен өйрәнүгә зур игътибар бирә.

М. Мәхмүдов үзенең «Практическое руководство к изучению татарского языка» дигән хезмәтендә рәвешләрнең дүрт семантик төркемен аерып чыгара: күләм (*ничә – сколько, күп – много, азрак – меньше*), эш-хәлнең үтәлү рәвешен белдергән лексик берәмлекләр (*алай – так, бергә – вместе, яшерен – скрытый*), урын (*ни җирдә – где, кая – куда, бу төштә – здесь*), вакыт (*ул вакыт – тогда, инде – уже, кичә – вчера*) [9, б. 212–221]. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: автор беренче тапкыр семантик төркемнәрнең исемнәрен билгеләүдә «эш-хәлнең үтәлү рәвешен белдергән рәвешләр» атамасын куллана.

Татар халкының күренекле мәгърифәтчесе К. Насыйри исә рәвешләрне бәйлек һәм бәйлек сүзләр белән бергә карый. Галим аларны ун төркемчәгә бүлә: сорау (*кайда – где, ничә – сколько, кайчан – когда*), вакыт (*кичә – вчера, һәркайчан – всегда, төнлә – ночью*), урын (*монда – здесь, эчтә – внутри, анда – там*), күләм (*аз – мало, күп – много, якын – близко*), билге (*яхшы – хороший, акрын – медленно, тиз – быстро*), раслау (*шулай – так, әйе – да, алай – так*), юклык (*түгел – не, юк – нет*), чикләүче (*генә, гына, кенә – только*), дәрәҗә (*каты – жесткий, бик – очень*) һәм чагыштыру (*кебек – словно, -дай, сыман – словно*) [10, б. 9]. Әлеге грамматикада рәвешләр арасында хәзерге грамматикаларда мөстәкыйль һәм ярдәмче сүз төркемнәренә кергән сүзләр күп күзәтелә.

1869 елда Казанда алтай теле грамматикасы нәшер ителә, анда рәвеш ярдәмлек сүз төркемнәре составына кертелә, аерып әйткәндә, кисәкчә буларак билгеләнә. Әйтергә кирәк, бу грамматиканың авторлары кисәкчәләргә, рәвешләр белән беррәттән, бәйлекләрне һәм теркәгечләрне дә кертеп карыйлар [3, б. 204]. Алар рәвешләрнең алты төркемчәсен билгели: сыйфат дәрәҗәсе (*иң – самый*), вакыт (*иртән – утром*), урын (*анда – там*), күрсәтү (*муна – вот*) һәм -*мы/-ме* сорау кисәкчәләре ярдәмендә ясалган сорау рәвешләре [11, б. 94–102].

1895 елда Казан университеты типографиясендә К. Насыйриның «Әнмүзәҗ» исемле хезмәте дөнья күрә. Әлеге грамматиканы язуда авторга гарәп һәм рус лингвистика мәктәпләренең йогынтысы сизелә [3, б. 204]. Ләкин галим аларның берсенә дә сукырларча иярми, ә татар теленә хас булган үзенчәлекләрне исәпкә алып өйрәнә. «Әнмүзәҗ» хезмәтендә К. Насыйри рәвешләрне «зарыф» дигән термин белән атый һәм «...эш яки хәлне билгеләү өчен кулланылуын» искәртә [12, б. 133-134]. Галим фикеренчә, «зарыф» икегә – вакыт рәвешләренә («зарфы заман») һәм урын рәвешләренә («зарфы урын») бүленә. Вакыт рәвешләренә К. Насыйри *бүген, көндез, төнлә, әле, иртә белән, яз көне* кебек сүзләрне кертә. Ә урын рәвешләренә *анда, монда, шунда, тегендә, эчтә, тышта, уңда, аттта, алда* кебек мисаллар китерә [12, б. 135–139]. Күргәнебезчә, әлеге мисаллар арасында мәгънәләре буенча рәвешләргә якын торган башка сүз төркемнәре дә очрый.

Г. Нугайбәк «Төрлек» исемле хезмәтендә исә рәвешләрне «җитәкчеләр» дип атый һәм аларның урынны, вакытны, эш-хәлнең рәвешен белдергән сүзләр булуын күрсәтә [13, б. 68], әлеге сүзләрнең фигыльләрне ачыклап килүен ассызыклый. Галим, беренчеләрдән булып, татар телендә рәвешләрнең төрләнми торган сүз төркеме булуын билгели. Ул хәл фигыль (*карый бардым*) һәм инфинитив (*карарга бардым*) формаларын да рәвеш сүз төркеменә кертеп карый. Ясалышлары буенча галим аларны икегә бүлә: «билгелек» һәм «тормышлык» рәвешләре. Беренче төркемгә *ничек?* соравына җавап биргән (*тиз йөри, татарча сөйләшә*) рәвешләрне, ә икенчесенә – «күрсәтү өчен йөргән» рәвешләрне (*төнлә кайтты, югарыда тора*) кертә [13, б. 68]. Шуны да искәртергә кирәк: әлеге грамматикада рәвеш сүз төркеменә китерелгән мисаллар арасында бәйләгеч һәм модаль мәгънәле сүз төркемнәренә караган сүзләр инде күзәтелми. Шулай ук, галим парлы рәвешләргә күпсанлы мисаллар китерә (*тырт-пырт, ашык-пошык*).

М. Корбангалиев белән Р. Газизов исә рәвешләрне ярдәмче сүзләр составына кертеп карыйлар. Авторлар татар телендә рәвешләрнең

морфологик яктан азрак үсеш алуын һәм шулай ук башка телләрдәге рәвешләргә татар телендә сыйфатлар белән исемнәрнең дә туры килүен искәртәләр. Алар рәвешләргә кергән сүзләрне тамыр (саф) һәм ясалма рәвешләргә аералар. Тамыр рәвешләр дип, «эш яки хәлнең үтәлү рәвешен яки билгесен белдерүче сүзләр»не атыйлар, ә ясалма рәвешләргә *-лай, -ләй (тереләй), -лата, -ләтә (акчалата), -ча, -чә (татарча)* кушымчалары ярдәмендә ясалган сүзләрне кертәләр [14, б. 97]. М. Корбангалиев белән Р. Газизов рәвешләрнең мәгънә төркемчәләрен тикшергәндә, шулай ук рус грамматикаларына таяналар. Алар урын (*кайда*), вакыт (*бүген*), сәбәп (*юкка*), раслау (*бар*), юклык (*юк, түгел*), икеләнү (*бәлки*), билгеләү (*бераз*), сорау (*ничек*), чикләүче (*гына, генә*) дип аталган мәгънә төркемчәләрен күрсәтәләр. Моннан тыш, галимнәр әлеге сүз төркеменә кергән сүзләрнең җөмләдә төрле хәлләр булып килүен һәм бу үзенчәлекнең рәвешләрне башка сүз төркемнәреннән аерырга ярдәм итүен ассызыклап, беренчеләрдән булып, рәвешләрнең җөмләдәге вазифаларын билгелиләр. Шуны да искәртеп үтәргә кирәк: XX гасыр башында чыккан хезмәтләр арасында бары тик М. Корбангалиев һәм Р. Газизов грамматикасында гына рәвешләргә хас булган чагыштыру дәрәҗәсе турында әйтелә.

Г. Алпаров фикеренчә, «әгәр сыйфатлар исемнәрнең рәвешләре булса, рәвешләр – фигыльләрнең сыйфатлары» [15, б. 55]. Галим рәвешләрнең үзенчәлекле сүз төркеме булуын искәртә һәм, беренчеләрдән булып «рәвеш» (фарсы сүзе) терминын куллана. Ул аларның түбәндәге ясалу юлларын күрсәтә:

1) *-лай, -ләй* кушымчалары белән алмашлыклардан (*алай, болай, шулай, тегеләй, бөтенләй*) ясала;

2) *-лата, -ләтә* кушымчалары ярдәмендә башка сүз төркемнәреннән (*икеләтә, акчалата, көмешләтә, кичләтә, әйберләтә*) ясала;

3) *-тын, -тен, -ын, -ен, -н* кушымчалары ярдәмендә урын-вакыт сүзләреннән (*якынтын, яшертен, кичен*) [15, б. 78] ясала.

Күргәнебезчә, Г. Алпаров рәвешләрне ясалу ысуллары буенча төркемләүгә шактый зур игътибар бирә.

Шул рәвешле XIX гасырдан башлап XX гасыр башларына кадәр татар телендә язылган грамматикаларда рәвеш сүз төркеме рус грамматикаларына нигезләнеп тәкъдим ителә [3, б. 204]. Шул ук вакытта әлеге тел берәмлегенә билгеләмә биргәндә, авторлар әлеге сүзләрнең лексик мәгънәләренә басым ясыйлар. Нигездә, рәвешләр фигыльләр һәм исемнәр алдында килеп, төрле хәлләр функциясен үтәүче сүзләр буларак билгеләнә. Ләкин бу чорда дөнья күргән хезмәтләрдә әлеге сүз төркеменең асылы турында төгәл күзаллаулар чагылыш тапмый, шуңа күрә аларның үзенчәлекләрен билгеләүдә кайбер төгәлсезлекләр күзәтелә. Шуңа күрә рәвешләр арасында башка сүз төркемнәренә караган сүзләр дә (алмашлыклар, модаль сүзләр, кисәкчәләр, бәйлекләр) урын ала, бу лексик берәмлекләрнең татар теленә тәрҗемәләре рус грамматикаларында күрсәтелгән сүзләрнең мәгънәләрен белдерә.

Әкренләп, XX гасырның 30 нчы елларында басылган грамматикаларда мөстәкыйль сүз төркемнәре рәтендә рәвеш тә тотрыклы урын ала башлый [4]. Бу, беренче чиратта, төрки телләрнең тулырак һәм җентекле грамматикалары дөнья күрү белән бәйле. Мәсәлән, тюрколог А.К. Боровков рәвешне «эш-хәлнең яки билгенең билгесе буларак кулланылучы төрләнми торган сүзләр категориясе» дип билгели [16, б. 76]. Галимнең сыйфат-рәвеш мөнәсәбәтенә бәйле фикерләре дә кызыклы. Уйгыр теле дәреслеге авторы рәвешләр һәм сыйфатлар арасында синтаксик чикне генә билгеләргә мөмкин һәм сыйфатлар фигыльнең үзлекләрен, билгеләрен белдергән, ачыклаган очракта синтаксик функцияләре буенча рәвешләргә кучәләр дип ассызыклый. Бу бәхәсле аспект, ягъни әгәр бер үк сүз җөмләдә аергыч вазифасын үтәсә – сыйфат, ә хәл булып килсә – рәвеш дип каралу, гомумән, сыйфат һәм рәвеш сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәтен ачыклау, үз чорында күп галимнәребезнең хезмәтләрендә яктыртыла (Х. Бәдигый, В.Н. Хангилдин, Ф.Ә. Ганиев һ.б.).

Татар телендәге сүз төркемнәре төрки телләр белән аеруча зур уртаклык күрсәтәләр [17, б. 25], шуңа күрә татар телендә сүз төркемләү мәсьәләсен, безнең очракта рәвешнең мөстәкыйль сүз төркеме буларак формалашу үзенчәлекләрен тикшергәндә, төрки телләр белемендә бу мәсьәләгә карата әйтелгән фикерләрне өйрәнү шулай ук зур әһәмияткә ия. Мәсәлән, башкорт теле грамматикасы авторы Н. К. Дмитриев рәвешнең грамматик категория булуын ассызыклый һәм әлеге тел берәмлеге «эшнең, хәрәкәтнең билгесен (фигыльнең) яки билгенең билгесен (сыйфатның) күрсәтә» дип билгели [18, б. 112]. Шул рәвешле, бу сүз төркеменең фигыль һәм сыйфат белән

бәйләнешенә игътибар итә. Моннан тыш, үзенең төрек (1939), кумык (1940), башкорт (1948) теле грамматикаларында Н.К. Дмитриев рәвешләрне формалашып бетмәгән морфологик категория буларак билгеле һәм төрки телләрдә әлеге сүз төркеменең өзлексез тулылана, байый баруын ассызыклый [4].

Бер үк вакытта галим рәвешләрнең исемнәрне, ә сыйфатларның фигыльләрне ачыклап килүен таный: *татарча яза – татарча китап*; *яхшы бала – яхшы укый*. [3, б. 204]. Шуңа бәйле рәвештә, Н.К. Дмитриевнең сыйфат-рәвеш мөнәсәбәте турында әйткән сүзләре кыйммәт: «татар телендәге сүз төркемнәрен анализлау өчен аерым сүз семантикасы хәл итүче элемент булып тора. Бу яктан караганда, мәсәлән, «яхшы» сүзе татар теле өчен бердәм зурлыкны күрсәтә, логик яктан ул атрибут, билге төшенчәсе белән бәйле, шуңа күрә аны бернинди икеләнүләрсез сыйфат сүз төркеме составына кертергә кирәк. Татар теле өчен «яхшы» сүзе, нинди синтаксик функция (хәл яки аергыч) үтәвенә карамастан, морфологик яктан сыйфат булып кала» [18, б. 70-71]. Бер үк сүзне, синтаксик функциясенә карап, бер очракта сыйфат дип, икенче очракта рәвеш дип билгеләүгә каршы чыккан әлеге фикерләр алга таба Д.Г. Тумашева, Ф.Х. Хисамова, Ч.М. Харисова кебек татар галимнәренең хезмәтләрендә дә яктыртыла: «Әгәр дә сүзнең семантикасында билге төсмере көчле булса, аларны аергыч яки хәл булып килүләренә карамастан, сыйфат дип карарга кирәк: *сөйкемле кыз, сөйкемле сөйләшә* һ.б. Мондый очракларны сыйфатларның рәвеш ролендә килүе һәм, киресенчә (*күп кеше, татарча китап* һ.б.) рәвешнең сыйфат ролендә йөрүе дип бәяләү мәсьәләне хәл итүдән ерак тора...» [19, б. 83].

Хакас телендәге рәвешләрне тасвирлап, Н.П. Дыренкова өйрәнелә торган тел берәмлекләренең морфологик яктан исемнәргә, сыйфатларга, саннарга, алмашлыкларга, фигыльләргә якын торуына басым ясый. Ул аерым сүзнең кайсы сүз төркеменә керүен билгеләү өчен сорау куеп карарга һәм сорау сүзенең семантик-грамматик эквивалентлыгына таянырга тәкъдим итә [20].

Якут теле белгече Л.Н. Харитонов фикеренчә исә, «якут телендә рәвешләр семантик, синтаксик һәм морфологик билгеләре буенча барлык башка сүзләрдән ачык аерылып торган сүзләрнең мөстәкыйль төркемен тәшкил итә» [21, б. 5]. Галим искәртеп үткәнчә, сүзнең статусын билгеләү өчен аның мәгънәви, синтаксик һәм морфологик үзлекләренең бердәм җыелмасын карарга кирәк.

А.Н. Кононовның төрек теле грамматикасы китабында да рәвешкә зур урын бирелә. Рәвешне «эш-гамәл, билге һәм предмет билгесен белдерүче, төрләнми торган сүз төркеме» дип билгеләп, галим аның фигыль, сыйфат һәм исем белән бәйләнешен күрсәтә [22, б. 274]. А.Н. Кононов рәвешләрнең 4 мәгънә төркемчәсен билгели: билге, күләм, билге-хәл һәм хәл рәвешләре [22, б. 309]. Әлеге хезмәттә рәвешләрнең ясалыш ысуллары анализлана, бигрәк тә конверсия күренешен тасвирлауга зур игътибар бирелә.

Бүгенге көндә рәвеш – «эш, хәл билгеләренең, сирәгрәк предмет һәм затларның процесска бәйле булмаган билгеләрен белдерә торган сүз төркеме» [23, б. 318] буларак билгеләнә, лексик-грамматик билгеләре буенча билге һәм хәл рәвешләренә бүленә. Билге рәвешләренә эш-хәлнең үтәлү рәвешен белдергән рәвешләр (*аягүрә, тын, берьюлы*) һәм күләм-чама рәвешләре (*бик, шактый, күп*), ә хәл рәвешләренә урын (*ерак, югары, ары*), вакыт (*хәзер, бүген, көндез*), сәбәп-максат (*юри, тикмәгә, заяга*) рәвешләре кертелә [23, б. 320]. Лексик-семантик мәгънәләре буенча рәвешләр сыйфатларга якын, чөнки икесе дә билге төшенчәсе белән бәйле. Морфологик яктан рәвеш төрләнми торган сүз төркеме, бары тик кайбер рәвешләр генә дәрәҗә формаларын ала. Синтаксик яктан рәвешләр күбрәк фигыльне, сыйфатны яки башка бер рәвешне ачыклап, хәл функциясендә киләләр. Мәсәлән: *Яңгыр* ***сирәк*** *сибәләп кенә торды да, туктап тын алгач,* ***чиләкләп*** *ора башлады. (М. Хуҗин).* ***Гәрәбәдәй*** *сап-сары чикләвек аның учына тәгәрәп төште. (Ф. Шәфигуллин). Элек Илсөяр бу тауга менгәнен сизми дә кала иде, бу юлы* ***бигрәк*** *озак тоелды (Г. Гобәй.)* Кайбер рәвешләр исә исемне ачыклап, аергыч функциясендә дә киләләр. Мәсәлән:

*Җырлар түгел, җилләр җитә алмас*
***Ерак*** *җирдә күлмәк иясе. (М. Җәлил).*

Аерым очракларда әлеге тел берәмлеге җөмләдә хәбәр булып килергә дә мөмкин. Мәсәлән: *Зирәк һәр җирдә кирәк, тик чын зирәк* ***бик сирәк*** *(мәкаль).* Санап кителгән әлеге үзенчәлекләр (лексик-семантик, морфологик һәм синтаксик) рәвешнең мөстәкыйль сүз төркеме булуын раслый.

### Төп нәтиҗәләр

Шул рәвешле, без XIX гасыр башыннан алып, бүгенге көнгә кадәр басылган грамматикаларда рәвешләрнең өйрәнелү тарихына кыскача күзәтү ясап чыктык. Бу сүз төркемен тикшерүгә галимнәр төрлечә якын килгәннәр. Грамматикаларда рәвешләр турында мәгълүмат биргәндә, шактый гына бәхәсле фикерләр күзәтелә. XIX-XX гасыр башында рәвешләр сыйфат, кайвакыт хәл фигыль һәм ярдәмче сүз төркемнәре составында карала. Кайбер галимнәребез рәвеш белән сыйфат, хәл фигыль, ярдәмче сүз төркемнәре арасында чикне билгеләүдә XX гасырның урталарына кадәр шактый зур кыенлыклар кичерәләр. Ә инде бу чордан соң дөнья күргән грамматикаларда рәвешләрне тасвирлауда бертөрлелек саклана башлый [24, б. 156; 25, б. 282]. Алар лексик мәгънәләреннән, морфологик билгеләреннән һәм синтаксик вазифаларыннан чыгып билгеләнәләр.

**Әдәбият**


1. Султанбаева Х. В. К проблеме частей речи в языках различного типологического строя // Актуальные проблемы филологии и педагогической лингвистики. 2019; 2: 12-18. DOI: 10.29025/2079-6021-2019-2-12-18.
2. Gafarova V. R., Galiullina G. R Tatar language non-derivative verbs in historical perspective // Journal of Language and Literature. – Volume 6, Issue 2, 1 May 2015, Pages 128–131.
3. Харисова Ч.М., Шакирова Г.Р. Наречие в исторической структуре частей речи в татарском и других тюркских языках // Филологические науки: Вопросы теории и практики. Часть 2. Тамбов. – № 6 (60). – 2016. С. 203–206.
4. Шакирова Г. Р. Наречие в татарском языке: лингводидактический аспект / Г. Р. Шакирова. – Казань: Отечество, 2017. 172 с.
5. Гиганов И. Грамматика татарского языка. СПб.: Импер. акад. наук, 1801. 264 с.
6. Троянский А. Краткая татарская грамматика в пользу учащегося юношества, сочиненная Казанской Академии Учителем татарского языка священником А. Троянским / А. Троянский – СПб., 1814. 200 с.
7. Троянский А. Краткая татарская грамматика священника А. Троянского. Казань: Тип. Коковиной, 1860. 234 с.
8. Казем-Бек А. Грамматика турецко-татарского языка, составленная ординарным Профессором Мирзою Александром Казем-Беком / А. Казем-Бек. – Казань: Университетская типография, 1839. 524 с.
9. Махмудов М. Г. Практическое руководство к изучению татарского языка, сост. старшим учителем 2-ой Казанской гимназии Махмудовым / М. Г. Махмудов. – Казань, 1857. 255 с.
10. Насыри К. Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах / К. Насыри. – Казань: Университетская тип., 1860. – 80 с.
11. Грамматика алтайского языка, составленная членами Алтайской миссии. – Казань: Университетская тип., 1869. 300 с.
12. Насыйри К. Әнмүзәҗ. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1975. 213 б.
13. Нугайбәк Г. Төрлек / Г. Нугайбәк. – Казань: Лито-тип. И.Н. Харитонова, 1911. 80 б.
14. Курбангалиев М. Х., Газизов Р. С. Опыт краткой практической систематической грамматики татарского языка: часть I. Фонетика и морфология / М. Х. Курбангалиев, Р. С. Газизов. – Казань: Государственное издательство ТССР, 1925. 104 с.
15. Алпаров Г. Х. Шәкли нигезендә татар грамматикасы (Телебезне гыйльми тикшерү юлында бер тәҗрибә). Казан: Татар. дәүл. нәшр., 1926. 164 б.
16. Боровков А. К. Учебник уйгурского языка. Л.: Изд-во Лен. вост. ин-та, 1935. 248 с.
17. Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле. Морфологиясе. – Казан: Казан университеты нәшр., 1978. 221 б.
18. Дмитриев Н. К. Грамматика башкирского языка. М. – Л.: Изд-во АПН СССР, 1948. 276 с.
19. Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. – Казан: КДУ нәшр., 1964.
20. Дыренкова Н. П. Грамматика хакасского языка. Фонетика и морфология. Абакан: Хакоблнациздат, 1948. 124 с.
21. Харитонов Л. Н. Неизменяемые слова в якутском языке. Якутск: Якут. изд-во, 1943. 84 с.
22. Кононов А. Н. Грамматика современного турецкого литературного языка. М. – Л.: Изд-во АН СССР, 1956. 569 с.
23. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. –Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2016 – Т. II. 432 б.
24. Харисова Ч. М. Татар телендә сүзләрне төркемләү принциплары // Millimədəniət. Qazan: Afyonkarahisar, 2014. B. 155-157.
25. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: Югары уку йортлары өчен дәреслек / Ф. М. Хисамова. – Казан: Мәгариф, 2006. 335 б.

# ИЗУЧЕНИЕ НАРЕЧИЯ В ДИАХРОНИЧЕСКОМ АСПЕКТЕ В ТАТАРСКОМ И ДРУГИХ ТЮРКСКИХ ЯЗЫКАХ

**Гульнара Расиховна Шакирова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
shakirova25@mail.ru.

Статья посвящена изучению наречия в диахроническом аспекте в татарском и других тюркских языках. На протяжении всей истории развития тюркского языкознания эта группа слов всегда привлекала внимание ученых. В татарском языке наречия начали изучаться в начале XIX века. В статье рассматриваются различные подходы, принципы и положения, содержащиеся в трудах известных лингвистов татарского и других тюркских языков: Г. Алпарова, И. Гиганова, Н. К. Дмитриева, А. Казем-Бека, А. Н. Кононова, К. Насыйри, Г. Нугайбека, А. Троянского и других. Освещаются проблемы, связанные с формированием наречия как самостоятельной части речи, его лексико-семантических групп. Наречия в татарском и других тюркских языках не дифференцированы от других частей речи какими-либо специфическими показателями, кроме словообразующих аффиксов. Следовательно, актуальной является системная характеристика наречия. В статье была предпринята попытка систематизировать теоретический материал по этому вопросу.

**Ключевые слова:** татарский язык, самостоятельная часть речи, диахронический аспект, наречие, языкознание, морфология